# Тема: Алмашлыклар турындагы белемнәрне ныгыту

Хәерле көннәр сезгә.

Зиһен һәм тел ачкычлары

Телимен һәммәгезгә!

## Дустым Алсу!

Минем бик якын дустым бар.Анның исеме Алсу. Алсу өченче сыйныфта укый. Алсуга 9яшь. Алсу бик яхшы укучы. Алсу спортны ярата. Без Алсу белән төрле спорт түгәрәкләренә йөрибез. Мин Алсу белән бик горурланам.

Дустым Алсу!

Минем бик якын дустым бар.

Аның исеме Алсу.Ул өченче сыйныфта укый.Аңа 9яшь.Алсу бик яхшы укучы.

Ул спортны ярата.Без аның белән төрле спорт түгәрәкләренә йөрибез.

Мин Алсу белән бик горурланам.

Алмашлык мөстәкыйль сүз төркеме.

Алмашлык исемне алмаштырып килә.

Кем? Нәрсә? сорауларына җавап булып килә.

Җөмләнең иясе булып килә.

Җөмләдә кабатлаулар булмасын өчен кирәк.

Килеш белән төрләнә.

# Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше

| Килешләр | 1 зат | 2 зат | 3 зат |
| --- | --- | --- | --- |
| Баш килеш | Мин | Син | Алар |
| Иялек килеше | Минем | Синең | Аларның |
| Юнәлеш килеше | Миңа | Сиңа | Аларга |
| Төшем килеше | Мине | Сине | Аларны |
| Чыгыш килеше | Миннән | Синнән | Алардан |
| Урын-вакыт килеше | Миндә | Синдә | Аларда |

Безнең бабай гаиләдә иң олы кеше.
Аңа хәзер туксан яшь,миңа тугыз яшь.
Без бабай белән сөйләшергә
яратабыз.
Бабай миңа үзенең яшьлеген сөйли.
Ә мин аңа мәктәптәге хәлләрне
сөйләргә
яратам. Безгә бергә бик күңелле.

# Тест җаваплары

1. ә)исемне
2. ә)мин,без
3. б)син,сез
4. б)ул,алар
5. б) ул
6. ә)безнең,аларның
7. ә)миндә,анда
8. ә)Сез
9. ә)аңа,аңар,аңарга
10. ә)миңа,сиңа,аңа

# Алмашлыклар кулланып,”Мәктәп бакчасында” дигән темага инша язарга

Өйгә эш



# Үз эшеңне бәялә



Дәрес материалын бик әйбәт үзләштердем, хәтта иптәшләремә дә булыша алам.



Әйбәт эшлим, материалны аңладым.



Әйбәт эшлим, ләкин үз  иптәшемнең ярдәменә каршы килмим.



# Дәрес өчен рәхмәт!
# Булдырдыгыз!

